КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Кырбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

20.11.2021 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2021 елның 20 нче ноябрендә узган гражданнар җыенында «2022 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Кырбаш торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Кырбаш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 900,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

1) Кырбаш торак пунктында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 66 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 53 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 53 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Кырбаш торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

1. «2022 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Кырбаш торак пунктында Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Кырбаш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 900,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә” һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

1) Кырбаш торак пунктында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Шәмәрдән авыл
җирлеге башлыгы

А.Н.Гәрәев